КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 19 март

г.Казань

№ б-462

Татарстан Республикасының торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны халыкның экология һәм санитария-эпидемиология иминлеге таләпләренә җавап бирә торган хәлгә китерү максатларында:

1. 2026 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасының торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча ике айга исәпләнгән санитария-экология айлыгын (алга таба – ике айлык) игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

ике айлык үткәрү турындагы мәгълүматны оешмалар җитәкчеләренә һәм халыкка җиткерүне;

2026 елның 19 мартына кадәр ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар чистарту планнарын эшләүне һәм әлеге расланган планнарны, шулай ук ике айлык үткәрү эшләрен координацияләү максаты белән булдырылган оператив штаблар турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрүне;

җирле үзидарә органнарының муниципаль районнар һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрнең, калдыклар белән эш итү буенча муниципаль кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтү өлешендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары эшләрен активлаштыруны;

су объектларының су саклау зоналарын, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм киемнәр базарларын, халыкның күпләп ял итү урыннарын, ял базаларын, бакчачылык җәмгыятьләрен һәм гараж кооперативларын, хосусый торак секторы территорияләрен, автомобиль юлларының юл буе полосаларын санитар чистарту буенча, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм карап тоту буенча чаралар үткәрүне;

каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү, шулай ук алар янындагы урыннарны санитар чистартуны тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрүне;

иҗтимагый яшьләр (волонтерлык) оешмаларын ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә ирекле нигездә җәлеп итүне;

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә барлыкка килгән калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары мониторингын гамәлгә ашыруны;

атна саен, чәршәмбе, 12 сәгать 00 минутка кадәр 1, 2 нче кушымталарда бирелгән форма буенча ике айлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына кертүне.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә, Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә:

җитештерү һәм куллану калдыклары, махсус сакланылучы табигать территорияләренең санитария торышы, торак фондын төзү, файдалану һәм карап тоту гамәлгә ашырыла торган территорияләрдә җир кишәрлекләренең санитария-экология торышы белән эш итү өлкәсендә табигатьне саклау законнары таләпләренең үтәлешен тикшерүдә тотуны һәм күзәтүне көчәйтергә;

торак пунктлар, шәһәр яны урманнары, су объектларының су саклау зоналары, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар, халыкның күпләп ял итү урыннары, ял базалары, бакчачылык җәмгыятьләре һәм гараж кооперативлары территорияләрендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын бетерү мәсьәләләренә аерым игътибар бирергә;

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарның калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру турында мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм сыйфатлы карап тикшерүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә атна саен, чәршәмбе, 12 сәгать 00 минутка кадәр 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына җибәрергә, шулай ук Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Табигатьтән файдалану өлкәсендә

күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә әлеге мәгълүматны әлеге Министрлыкка җибәрүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына атна саен, чәршәмбе, 12 сәгать 00 минутка кадәр Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына ике айлык кысаларында үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре турында мәгълүмат җибәрергә.

6. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территорияләре торышын тикшерү максаты белән күчмә чаралар үткәрү өчен «Матди тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына ягулык-майлау материалларының өстәмә санын бирүне контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

7. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында ике айлык кысаларында үткәрелә торган эшләрне массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына 2026 елның 5 июненә кадәр ике айлык йомгаклары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 10 март, б-486 нчы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

10. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 19 март, б-462 нче
боерыгына 1 нче кушымта

2026 елның «____» ______________на карата ведомстволар эше турында
мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Бозулар ачыкланды | | Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары ачыкланды | | | Калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннары бетерелде | | | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының) _______ статьясы буенча беркетмәләр төзелде, данә | | | | Административ җаваплылыкка тартылды | | | | Штрафлар салынды, мең сум | Штрафлар түләтелде, мең сум | Кисәтүләр бирелде |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шулардан бетерелде | саны, данә | мәйданы, кв.метр | күләме, куб.метр | саны, данә | мәйданы, кв.метр | күләме, куб.метр | барлыгы | юридик затларга | вазыйфаи затларга | гражданнарга | барлыгы | юридик затлар | вазыйфаи затлар | гражданнар | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче ___________________________________________ _____________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)

Искәрмә. әлеге кушымтага өстәмә рәвештә раслый торган фотосурәтне (ачыкланды/бетерелде) теркәп, хисап датасына карата мәгълүмат (арта бара торган йомгак белән) бирергә.

| Т/с | Хокук бозу урыны адресы | Мәйданы, кв.метр | Күләме, куб метр | Статусы (бетерелде / бетерелмәде) | Фотоматериал (ачыкланды/бетерелде) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 19 март, б-462 нче
боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының
2026 елның «___»__________ на карата санитария-экология ике айлыгын үткәрү эшләре барышы турында
мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Чыгарылган каты көнкүреш калдыклары күләме, куб.метр | | Махсус автотранспорт җәлеп ителде, берәмлек | Халык катнашты, кеше | Агачлар утыртылды, данә | Куаклар утыртылды, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән полигоннарга | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Җитәкче ____________________________________________ _____________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)

Искәрмә. Хисап датасына карата мәгълүмат (арта бара торган йомгак белән) бирергә.

_______________________________________